| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ — КАРАР

27.03.2025 — Зур Тигәнәле ав. — № 87

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карары проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга кертелгән үзгәрешләргә һәм өстәмәләргә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының XIV бүлегенә туры китереп

**Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы Карары проектын (алга таба – Карар проекты) 2 нче кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлегенең Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасы: Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал ур., 17 йорт;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлегенең "Әшнәк" кибете бинасы: Әшнәк авылы, Х.Вахит ур., 11 йорт.

4. Карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Мостафин Р.Р. – 1 нче Зур Тигәнәле сайлау округы буенча депутат, төркем җитәкчесе;

2) Әхмәтҗанов С.Җ. – 5 нче Зур Тигәнәле сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы;

3) Галимов И.Н. – 4 нче Зур Тигәнәле сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы.

5. Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы депутатларының карар проектына тәкъдимнәре комиссиягә төзәтмәләр рәвешендә 2025 елның 24 апреленә кадәр кертелә дип билгеләргә.

6. Гражданнарның карар проектына тәкъдимнәре, Ф.И.А., туган елын, авторның адресын күрсәтеп, комиссиягә язма рәвештә түбәндәге адрес буенча җибәрелә дип билгеләргә: ТР, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал ур., 17 йорт.

7. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча 2025 елның 30 апреленә 10-00 сәгатьтә гавами тыңлаулар билгеләргә. адресы: ТР, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал ур., 17 йорт.

Гавами тыңлаулар Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының 27.12.2006ел, №19 карары белән расланган Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибенә туры китереп үткәрелә.

8. Комиссиягә җирлек Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм гражданнарның карар проектына тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, аларны эшләп бетерергә һәм 2025 елның 05 маена кадәр җирлек Советы каравына кертергә тиеш.

9. Әлеге карар, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **М.Ә.Гатин**

Зур Тигәнәле авыл җирлеге
Советының 27.03.2025 ел, № 87
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу**
**ТӘРТИБЕ**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәре Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: ТР, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал ур., 17 йорт, язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф. И. А., адрес, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр гавами тыңлаулар уздырылырга 7 көн кала кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: ТР, Алексеевск районы Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал ур., 17 йорт, язма рәвештә шәхсән яисә почта аша.

Гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына һәм Башлыгына тапшырыла.

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **М.Ә.Гатин**

Зур Тигәнәле авыл җирлеге
Советының 27.03.2025 ел, № 87
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**1. 1 статьяның 2 өлешенә** түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:
«Муниципаль берәмлекнең кыскартылган исеме-ТР АМР Зур Тигәнәле авыл җирлеге.»;

**2. 7 статьяның 1 өлешенә** түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:
«21) "Шәхси ярдәмче хуҗалык турында" 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

**3. 46 статьяның 1 өлешенә** түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт өстәргә:
«10.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

**4. 53 статьяның 2 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Җирлек башлыгын отставкага җибәрү өчен нигез булып тора:
1) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 75 статьясындагы 1 өлешенең 2 һәм 3 пунктларында каралган нәтиҗәләргә китергән (китергән) җирлек башлыгының карарлары, гамәлләре (гамәл кылмавы);
2) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, әлеге Уставта каралган җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү, вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бурычларын һәм (яисә) җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү бурычларын өч ай һәм аннан да күбрәк вакыт эчендә үтәмәү;
3) Җирлек Советы тарафыннан Җирлек Советы алдында еллык хисабы нәтиҗәләре буенча Җирлек Башлыгының эшчәнлегенә ике тапкыр рәттән канәгатьләнмәслек бәя бирелү;
4) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларның счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында»

2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, бурычларны үтәмәү;
5) анық чит ил агенты статусын алуы;
6) Җирлек башлыгы, Башкарма комитет, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарәсенең башка органнары һәм вазыйфаи затлары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан расасына, милләтенә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка хәлләргә бәйле рәвештә кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлегенең дәүләт гарантияләрен массакүләм бозуга, раса, милләт, тел яисә дин билгеләре буенча хокукларны чикләүгә һәм дискриминацияләүгә юл кую, әгәр бу милләтара һәм конфессияара татулыкны бозуга китерсә һәм милләтара (этникара) һәм конфессияара конфликтлар килеп чыгуга китерсә;
7) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләргә системалы рәвештә ирешмәү.»;

**5. 56 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:
«- "Шәхси ярдәмче хуҗалык турында" 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.».

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **М.Ә.Гатин**